| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАРАДУВАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАДУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_25_» ____03______2026 ел_ № _10__

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозуларны кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2014 елның 24 октябрендәге 47 номерлы карары белән расланган Карадуган авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозуларны кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә (эш бирүче) хәбәр итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.Эшкә алучының (эш бирүченең) вәкиленә, прокуратура органнарына яисә башка дәүләт органнарына аны коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында, башка дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциячел хокук бозуларны кылу фактлары, белешмәләрне тапшырмау, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, ялган белешмәләр тапшыру яисә керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү фактлары хакында хәбәр иткән муниципаль хезмәткәр Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яклавында тора».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Карадуган авыл җирлеге башлыгы: Ш.В.Низамиев